# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об Уполномоченном по правам ребенка в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
5 июня 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 1 августа 2011 года № 59-ЗРТ «Об Уполномоченном по правам ребенка в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 8; 2013, № 11 (I часть); 2014, № 6 (II часть) следующие изменения:

1) в преамбуле слово «избрания» заменить словом «назначения»;

2) в статье 1:

а) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Должность Уполномоченного по правам ребенка в Республике Татарстан (далее – Уполномоченный по правам ребенка) учреждается в соответствии с Конвенцией ООН о правах ребенка, Конституцией Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, Федеральным законом от 27 декабря 2018 года № 501-ФЗ «Об уполномоченных по правам ребенка в Российской Федерации» в целях обеспечения дополнительных гарантий эффективного функционирования механизмов реализации, соблюдения и защиты прав и интересов детей органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления в Республике Татарстан, образовательными и медицинскими организациями, организациями, оказывающими социальные и иные услуги детям и семьям, имеющим детей, и должностными лицами.»;

б) в части 3 слова «и неподотчетен каким-либо органам государственной власти Республики Татарстан, органам местного самоуправления в Республике Татарстан и должностным лицам» заменить словами «от каких-либо государственных органов, органов местного самоуправления и должностных лиц»;

3) в части 1 статьи 3:

а) дополнить пунктом 1[1] следующего содержания:

«1[1]) принятие в пределах своих полномочий мер по предупреждению и пресечению нарушения прав и интересов детей;»;

б) пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4) мониторинг и анализ реализации, соблюдения и защиты прав и интересов детей на территории Республики Татарстан;»;

в) пункт 6 изложить в следующей редакции:

«6) содействие эффективному функционированию государственной системы обеспечения реализации, соблюдения и защиты прав и интересов детей в Республике Татарстан, а также содействие взаимодействию органов государственной власти Республики Татарстан и органов местного самоуправления в Республике Татарстан по вопросам защиты прав и интересов детей;»;

г) пункт 8 изложить в следующей редакции:

«8) содействие развитию регионального и международного сотрудничества в области защиты прав и интересов детей;»;

д) дополнить пунктом 9 следующего содержания:

«9) участие в реализации единой государственной политики в области обеспечения и защиты прав и интересов детей;»;

е) дополнить пунктом 10 следующего содержания:

«10) участие в деятельности по профилактике безнадзорности и правонарушений несовершеннолетних.»;

4) в наименовании главы 2 слово «избрания» заменить словом «назначения»;

5) статью 5 изложить в следующей редакции:

«Статья 5. **Требования, предъявляемые к кандидату на должность Уполномоченного по правам ребенка**

На должность Уполномоченного по правам ребенка может быть назначен гражданин Российской Федерации не моложе тридцати лет, обладающий безупречной репутацией, имеющий высшее образование и опыт работы по реализации и защите прав и интересов детей, восстановлению нарушенных прав и интересов детей либо опыт правозащитной деятельности.»;

6) в статье 6:

а) в наименовании слово «Избрание» заменить словом «Назначение»;

б) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Уполномоченный по правам ребенка назначается на должность Государственным Советом Республики Татарстан большинством голосов от числа избранных депутатов Государственного Совета Республики Татарстан. До рассмотрения кандидатуры на должность Уполномоченного по правам ребенка Государственный Совет Республики Татарстан согласовывает ее с Уполномоченным при Президенте Российской Федерации по правам ребенка.»;

7) в части 2 статьи 7 слово «избрания» заменить словом «назначения»;

8) в статье 8:

а) в части 1 слово «избирается» заменить словом «назначается»;

б) в части 2 слово «избрано» заменить словом «назначено»;

в) в части 3 слово «избрания» заменить словом «назначения»;

9) в статье 10:

а) абзац первый части 2 изложить в следующей редакции:

«2. Досрочное освобождение Уполномоченного по правам ребенка от должности производится Государственным Советом Республики Татарстан по согласованию с Уполномоченным при Президенте Российской Федерации по правам ребенка. Решение о досрочном освобождении Уполномоченного по правам ребенка от должности принимается Государственным Советом Республики Татарстан большинством голосов от числа избранных депутатов Государственного Совета Республики Татарстан.»;

б) часть 3 признать утратившей силу;

10) в статье 11:

а) в пункте 2 слова «организаций независимо от их организационно-правовых форм и форм собственности» заменить словами «образовательных и медицинских организаций, организаций, оказывающих социальные и иные услуги детям и семьям, имеющим детей»;

б) в пункте 3 слова «организаций независимо от их организационно-правовых форм и форм собственности, осуществляющих деятельность по обеспечению прав и интересов детей» заменить словами «образовательных и медицинских организаций, организаций, оказывающих социальные и иные услуги детям и семьям, имеющим детей»;

в) пункт 5 изложить в следующей редакции:

«5) обращается в Государственный Совет Республики Татарстан с предложениями о проведении в порядке, предусмотренном законодательством Республики Татарстан, парламентских расследований, парламентских слушаний по фактам нарушения прав и интересов детей;»;

11) в части 1 статьи 12:

а) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1) безотлагательно быть принятым по вопросам своей деятельности руководителями либо лицами, временно исполняющими их обязанности, иными должностными лицами территориальных органов федеральных государственных органов, органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления в Республике Татарстан, образовательных и медицинских организаций, организаций, оказывающих социальные и иные услуги детям и семьям, имеющим детей;»;

б) пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2) запрашивать и получать в установленном порядке необходимые сведения, документы, материалы от территориальных органов федеральных государственных органов, органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления в Республике Татарстан, образовательных и медицинских организаций, организаций, оказывающих социальные и иные услуги детям и семьям, имеющим детей, их должностных лиц по вопросам, связанным с соблюдением и защитой прав и интересов детей;»;

в) пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3) по предъявлении удостоверения беспрепятственно посещать по вопросам своей деятельности территориальные органы федеральных государственных органов, органы государственной власти Республики Татарстан, органы местного самоуправления в Республике Татарстан, образовательные и медицинские организации, организации, оказывающие социальные и иные услуги детям и семьям, имеющим детей, расположенные на территории Республики Татарстан;»;

г) пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4) посещать учреждения, исполняющие наказания, и следственные изоляторы, в которых содержатся несовершеннолетние, беременные женщины и женщины, дети которых находятся в домах ребенка исправительных учреждений;»;

д) пункт 6 изложить в следующей редакции:

«6) самостоятельно или совместно с уполномоченными государственными органами и должностными лицами проводить проверку информации, изложенной в обращении на имя Уполномоченного по правам ребенка, содержащем жалобу, либо иной информации по вопросам, касающимся нарушения прав и интересов детей;»;

е) дополнить пунктом 11 следующего содержания:

«11) обращаться в суд с административными исковыми заявлениями о признании незаконными решений, действий (бездействия) органов государственной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, иных органов, организаций, наделенных отдельными государственными или иными публичными полномочиями, должностных лиц, государственных или муниципальных служащих в защиту прав и интересов детей, если полагает, что оспариваемые решения, действия (бездействие) не соответствуют нормативному правовому акту Российской Федерации, нарушают права и интересы детей, создают препятствия к реализации их прав и интересов или на них незаконно возложены какие-либо обязанности;»;

ж) дополнить пунктом 12 следующего содержания:

«12) направлять в органы государственной власти Республики Татарстан и органы местного самоуправления мотивированные предложения об издании (принятии) нормативных правовых актов, о внесении в нормативные правовые акты изменений, направленных на обеспечение реализации и соблюдения прав и интересов детей, признании нормативных правовых актов утратившими силу или приостановлении их действия в случаях, если эти акты нарушают права и интересы детей;»;

з) дополнить пунктом 13 следующего содержания:

«13) направлять Президенту Республики Татарстан, в Кабинет Министров Республики Татарстан мотивированные предложения о признании утратившими силу или приостановлении действия актов органов исполнительной власти Республики Татарстан в случаях, если эти акты нарушают права и интересы детей;»;

и) дополнить пунктом 14 следующего содержания:

«14) участвовать в пределах своих полномочий в деятельности по профилактике безнадзорности и правонарушений несовершеннолетних в порядке, установленном законодательством Российской Федерации и (или) законодательством Республики Татарстан.»;

12) в части 1 статьи 13:

а) в абзаце первом слова «доклад о своей деятельности и соблюдении прав и законных интересов ребенка в Республике Татарстан» заменить словами «доклад о результатах своей деятельности, содержащий в том числе оценку соблюдения прав и законных интересов детей на территории Республики Татарстан, а также предложения о совершенствовании их правового положения»;

б) абзац второй дополнить словами «, Уполномоченному при Президенте Российской Федерации по правам ребенка»;

13) в статье 14:

а) в части 2 слова «организаций независимо от организационно-правовых форм и форм собственности» заменить словами «образовательных и медицинских организаций, организаций, оказывающих социальные и иные услуги детям и семьям, имеющим детей»;

б) в части 4 слова «не позднее истечения года со дня нарушения прав и интересов ребенка или с того дня, когда заявителю стало известно об их нарушении» исключить;

в) часть 5 изложить в следующей редакции:

«5. Жалоба должна содержать фамилию, имя, отчество (последнее – при наличии), личную подпись и дату, если жалоба изложена в письменной форме, почтовый адрес, если ответ должен быть направлен в письменной форме, адрес электронной почты, если ответ должен быть направлен в форме электронного документа, изложение существа решений или действий (бездействия), нарушивших или нарушающих, по мнению заявителя, права и интересы ребенка.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
21 июня 2019 года
№ 51-ЗРТ

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 5 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8; 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «сайлану» сүзен «билгеләнү» сүзенә алмаштырырга;

2) 1 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил) вазыйфасы Бала хокуклары турында БМО конвенциясе, Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Россия Федерациясендә бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2018 елның 27 декабрендәге 501-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, мәгариф һәм медицина оешмалары, балаларга һәм балалы гаиләләргә социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтә торган оешмалар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, үтәү һәм яклау механизмнарының нәтиҗәле эшләвенә өстәмә гарантияләр тәэмин итү максатларында гамәлгә куела.»;

б) 3 өлештә «кайсы да булса Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга бәйсез һәм алар алдында хисап тотмый» сүзләрен «кайсы да булса дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга бәйле түгел» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$) балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозуны кисәтү һәм булдырмый калу буенча үз вәкаләтләре кысаларында чаралар күрү;»;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Татарстан Республикасы территориясендә балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга, үтәүгә һәм яклауга мониторинг үткәрү һәм анализ ясау;»;

в) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Татарстан Республикасында балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны, үтәүне һәм яклауны дәүләт тәэмин итү системасының нәтиҗәле эшләвенә ярдәм итү, шулай ук балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының үзара эшчәнлегенә булышу;»;

г) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә региональ һәм халыкара хезмәттәшлекне үстерүгә булышу;»;

д) түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9) балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;»;

е) түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10) балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау эшчәнлегендә катнашу.»;

4) 2 бүлек исемендә «сайлап кую» сүзләрен «билгеләп кую» сүзләренә алмаштырырга;

5) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатка куела торган таләпләр**

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына утыз яшьтән дә яшь булмаган, бик яхшы репутациягә ия, югары белемле һәм балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру һәм яклау, балаларның бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызу өлкәсендә эш тәҗрибәсе йә хокук яклау эшчәнлеге тәҗрибәсе булган Россия Федерациясе гражданы билгеләнеп куелырга мөмкин.»;

6) 6 статьяда:

а) исемендә «сайлап кую» сүзләрен «билгеләп кую» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфага Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан күпчелек тавыш

белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайлап куела. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны карауга кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы аны Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештерә.»;

7) 7 статьяның 2 өлешендә «сайланып» сүзен «билгеләнеп» сүзенә алмаштырырга;

8) 8 статьяда:

а) 1 өлештә «сайланып» сүзен «билгеләнеп» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «сайланып» сүзен «билгеләнеп» сүзенә алмаштырырга;

в) 3 өлештә «сайланган» сүзен «билгеләнгән» сүзенә алмаштырырга;

9) 10 статьяда:

а) 2 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне вазыйфасыннан вакытыннан алда азат итү, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештереп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне вазыйфасыннан вакытыннан алда азат итү турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.»;

б) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

10) 11 статьяда:

а) 2 пунктта «теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмаларның» сүзләрен «мәгариф һәм медицина оешмаларының, балаларга һәм балалы гаиләләргә социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтә торган оешмаларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган» сүзләрен төшереп калдырырга, «теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалар» сүзләрен «мәгариф һәм медицина оешмалары, балаларга һәм балалы гаиләләргә социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтә торган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу фактлары буенча Татарстан Республикасы законнарында каралган тәртиптә парламент тикшеренүләре, парламент тыңлаулары үткәрү турында тәкъдимнәр белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мөрәҗәгать итә;»;

11) 12 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча федераль дәүләт органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары,

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, мәгариф һәм медицина оешмалары, балаларга һәм балалы гаиләләргә социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтә торган оешмалар җитәкчеләре йә аларның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы затлар, бу органнарның, оешмаларның башка вазыйфаи затлары тарафыннан кичекмәстән кабул ителергә;»;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча федераль дәүләт органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарыннан, мәгариф һәм медицина оешмаларыннан, балаларга һәм балалы гаиләләргә социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтә торган оешмалардан, аларның вазыйфаи затларыннан билгеләнгән тәртиптә кирәкле белешмәләр, документлар, материаллар сорарга һәм алырга;»;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча федераль дәүләт органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына, мәгариф һәм медицина оешмаларына, балаларга һәм балалы гаиләләргә социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтә торган оешмаларга, таныклык күрсәтеп, каршылыксыз керергә;»;

г) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) балигъ булмаганнар, йөкле хатыннар һәм балалары төзәтү учреждениеләренең балалар йортларында булган хатыннар урнаштырылган җәза үтәтү учреждениеләренә һәм тикшерү изоляторларына керергә;»;

д) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил исеменә килгән шикаятьле мөрәҗәгатьтә бәян ителгән мәгълүматны йә балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозуга кагыла торган мәсьәләләр буенча башка мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә яисә вәкаләтле дәүләт органнары һәм вазыйфаи затлар белән берлектә тикшерергә;»;

е) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, аерым дәүләт вәкаләтләре яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән башка органнарның, оешмаларның, вазыйфаи затларның, дәүләт хезмәткәрләренең йә муниципаль хезмәткәрләрнең балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча карарлары, гамәлләре (гамәл кылмавы) Россия Федерациясе норматив хокукый актына туры килми, балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен боза, аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга комачаулык итә яисә аларга законсыз рәвештә ниндидер бурычлар йөкләнгән дип санаган очракта, дәгъва кылына торган карарларны, гамәлләрне (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында административ дәгъва гаризалары белән судка мөрәҗәгать итәргә;»;

ж) түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) норматив хокукый актлар бастырып чыгару (кабул итү) турында, норматив хокукый актларга балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә

ашыруны һәм үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү, норматив хокукый актлар балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозган очракларда, бу актларны үз көчен югалткан дип тану яисә аларның гамәлдә булуын туктатып тору хакында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына дәлилләнгән тәкъдимнәр җибәрергә;»;

з) түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары актлары балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозган очракларда, бу актларны үз көчен югалткан дип тану яисә аларның гамәлдә булуын туктатып тору хакында Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына дәлилләнгән тәкъдимнәр җибәрергә;»;

и) түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14) Россия Федерациясе законнарында һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә үз вәкаләтләре кысаларында балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау эшчәнлегендә катнашырга.»;

12) 13 статьяның 1 өлешендә:

а) беренче абзацта «үз эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турында еллык доклад» сүзләрен «үз эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә балалар хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешенә бәя бирелә торган, шулай ук аларның хокукый хәлен камилләштерү турында тәкъдимнәр булган еллык доклад» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «Прокурорына» сүзеннән соң «, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә» сүзләрен өстәргә;

13) 14 статьяда:

а) 2 өлештә «теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвештәге һәм милек рәвешендәге оешмалар» сүзләрен «мәгариф һәм медицина оешмалары, балаларга һәм балалы гаиләләргә социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтә торган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылган көннән яисә мөрәҗәгать итүчегә аларны бозу турында мәгълүм булган көннән алып бер елдан да соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әгәр шикаять язма рәвештә бәян ителгән булса, шикаятьтә фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), шәхси имза һәм дата, әгәр җавап язмача җибәрелергә тиеш булса, почта адресы, әгәр җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, электрон почта адресы, мөрәҗәгать итүче фикере буенча бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозган яисә боза торган карарларның яисә гамәлләрнең (гамәл кылмауның) асылы бәян ителергә тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 21 июнь
№ 51-ТРЗ